Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

18.05. 2022 ел № 96

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итү һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау турындагы” 2017 елның 31 июлендәге 97номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 4 өлеше ,Россия Федерациясе Президентының «Аерым категория затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне федераль дәүләт органнарының, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарының һәм оешмаларының рәсми сайтларында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны Бөтенроссия массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе» 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указының 2 пункты, Кама Тамагы районы прокурорының 2022 елның 29 мартындагы 02-08-02 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1.Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы » муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларына хәбәр итү һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау турындагы" 2017 елның 31 сентябрендәге 97 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә :

1.1. 3 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рәсми сайтларда гомумроссия массакүләм мәгълүмат чаралары да урнаштырыла, аларның ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында түбәндәге белешмәләр, шулай ук аларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бастырып чыгару өчен бирелә»;

1.2. 3 пунктта абзацларда, а), б), в), “вазыйфаи затка” сүзләрен “хезмәткәргә (эшчеләргә)” сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3 пунктта абзацны, г) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы (мондый алыш-бирешнең суммасы) хезмәткәрнең (хезмәткәрнең) һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә;

1.4. 4 пунктның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Рәсми сайтларда урнаштырыла торган һәм гомумроссия массакүләм мәгълүмат чараларына керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне бастырып чыгару өчен бирелә торган белешмәләрне күрсәтү тыела»;

1.5. 4 пунктта абзацларда, а), б), в), г) «вазыйфаи зат» сүзләрен «хезмәткәр (эшче)» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә.Габидуллинга йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
муниципаль район Советы рәисе Н.А.Вазыйхов